СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» ноябрь, 2023 ел Алабуга шәһәре № 296

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2020 елның 29 июлендәге 491 номерлы карары проектына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2020 елның 29 июлендәге 491 номерлы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Әлеге карар проектын гавами тыңлауларга чыгарырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга:

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе һәм гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы (2 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль

берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлауларны уздыру тәртибе ( 3 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны түбәндәге вакытка билгеләргә:

2023 елның 14 декабрендә 14.00 сәгатьтә Совет бинасының зур залында: Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 30 нчы йорт адресы буенча.

Гавами тыңлаулары нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып һәм алга таба раслау өчен Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы утырышы каравына чыгарырга.

6. 1 нче кушымтаның 2 нче һәм 4 нче пунктлары 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.М. Нуриев

Алабуга муниципаль районы
Советының
20 23 елның 296 номерлы
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

(алга таба - Устав)

1. Уставның 6 статьясындагы 1 өлешен 39 пункт белән тулыландырырга:
«39) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларны ачыклау һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыру».
2. Уставның 6 статьясындагы 1 өлешененең 26 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«26) җирле әһәмияттәге махсус саклапылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;».
3. 6 статьяның 1 өлешендәге 31 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«31) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;».
4. Уставның 6.1 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«14) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;».
5. Уставның 29 статьясында:
1) 7 өлешнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
2) 7 өлешнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында:
«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыклары (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.
6. Уставның 32 статьясының 1 өлешендәге 16 пунктчасын алып ташларга.
7. Уставның 40 статьясындагы 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыклары (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга.
8. Уставның 32 статьясында:
1) 5 өлешнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
2) 5 өлешнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында:
«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыклары (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.
9. Уставның 41 статьясына 7 өлеш түбәндәге редакциядә тулыландырырга:
«7. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм коррупциягә каршы тору максатыннан башка федераль законнар нигезендә, район Башлыгы чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган, әлегебурычларны үтәмәү аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип таныла.».
10. Уставның 49 статьясын 7.1. өлеше белән түбәндәге редакциядә тулыландырырга:
«7.1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм коррупциягә каршы тору максатыннан башка федераль законнар нигезендә, район Башкарма комитет җитәкчесе чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган, әлегебурычларны үтәмәү аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип таныла.».
11. Уставның 44 статьясында:

1) 6 өлешнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 өлешнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында:

«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга»;

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыклары (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.

12. Уставның 47 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;».

13. Уставның 50 статьясындагы 2 өлешенең 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.

14. Уставның 52 статьясындагы 1 абзацының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) район Башлыгы белән килештереп Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарлары билгеләп куя һәм вазифаларыннан азат итә, алар арасында бурычларны бүлеп бирә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм район Башкарма комитетының башка хезмәткәрләре вазифаларына билгели һәм вазифаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, ларның эшчәнлеген тикшереп тора, кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын күрә;».

15. Уставның 53 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыклары (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга.

16. Уставның 8 бүлеген алып ташларга.

17. Уставның 84 статьясындагы 7 өлешендә:

1) 3 абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыклары (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга.

Алабуга муниципаль районы
Советының
20 23 елның 296 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе һәм гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре:
Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 30 нчы йорт адресы буенча яисә кушымтада бирелгән үрнәк нигезендә, язма рәвештә 3-82-52 факсимиль элемтә ярдәмендә, түбәндәге таблица рәвешендә (кертелә) кабул ителә:

| N п/п | Тәкъдимнәр кертү инициаторы | Кертү датасы | Абзац, пункт, өлеш, статья | Проект тексты | Тәкъдимнәр тексты | Кертелгән тәкъдимне исәпкә алып, проект тексты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 7 | 8 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре:
423600, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 30 нчы йорт адресы буенча язма формада, авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын күрсәтеп тапшырыла.

Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы карары проекты рәсми рәвештә басылып чыккан көннән 2023 елның 12 декабренә кадәр, 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр эш көннәрендә кабул ителә.

3. Гавами тыңлауларда катнашу хокукы белән катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә:
423600, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 30 нчы йорт, шәхсән яисә почта аша («Устав турында фикер алышу» яки «Гавами тыңлаулары» дигән конверттагы тамга белән), шулай ук факс номеры буенча: 3-82-52.
4. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм, тиешенчә, гавами тыңлаулар үткәрү комиссиясенә тапшырыла.

Алабуга муниципаль районы
Советының
20 23 елның 296 номерлы
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлауларны уздыру тәртибе

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2009 елның 23 июнендәге 232 номерлы карары белән расланган һәм 2009 елның 19 августындагы 129 номерлы «Новая Кама» газетасында басылып чыккан Алабуга муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулары (алга таба - гавами тыңлаулар) уздырыла.

2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларында катнашучылар булып, гавами тыңлаулары уздырылганчы ике эш көне кала, язма рәвештә гариза бирүчеләр тора. Тәкъдимнәр кергән көн әлеге тәкъдимнәрне кабул итүче органга керү датасы булып тора.

3. Гавами тыңлауларында чыгыш ясау хокукы булмаган барлык кызыксынучы кешеләр катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулары башланганчы бер сәгать кала алдан башлана.

5. Гавами тыңлауларында район Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, район Советы рәисе урынбасары, район Советының даими комиссияләре рәисләре, район Башкарма комитеты җитәкчесе, район Башлыгы вәкаләтле башка затлар рәислек итә.

6. Гавами тыңлаулары рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләсенең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен, рәис тәкъдиме буенча гавами тыңлаулар секретаре (секретариат) сайлана.

8. Чыгышлар эзлеклелеге һәм вакыты, карала торган мәсьәләнең эчтәлеген, гавами тыңлауларда катнашуга һәм башка мәсьәләләрне исәпкә алып, гавами тыңлаулар уздыру регламенты белән билгеләнә.

9. Гавами тыңлауларында катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң, рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

10. Гавами тыңлаулар уздырганда тәртип саклау гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора. Гавами тыңлауларда катнашучылар җәмәгать тыңлаулары барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклары юк.

11. Рәислек итүче гавами тыңлаулар алып бара һәм гавами тыңлауларның көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышу тәртибен күзәтә, кирәк булганда, утырышлар залыннан мәсьәләләр буенча фикер алышу тәртибен бозучыларны алып ташларга хокуклы.

12. Гавами тыңлаулар уздырган вакытта беркетмә алып барыла. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретарьга (секретариатка) язма формада тапшырыла һәм гавами тыңлаулар беркетмәсенә теркәлеп куела.

13. Гавами тыңлаулар беркетмәсе рәис тарафыннан имзалана һәм район Советында саклана.

14. Мәҗбүри йомгаклау документы булып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә тора, әлеге документ гавами тыңлаулар узган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында рәсми бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

15. Гавами тыңлауларны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Алабуга муниципаль районы Советы тарафыннан башкарыла.